**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегенең Түреш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында «2023 елның 17 ноябрендәге 4 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

**№4** **02.04.2024 ел**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2024 елның 2 нче апрелендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегенең Түреш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның «17" ноябрендәге 4 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә ризамы:

Сез, 2024 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегенең Түреш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга 1500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларына, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар һәм локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 750 (җиде йөз илле) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә, Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән һәм контракт төзегән гражданнарны, һәм шулай ул хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә» һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруга юнәлтү:

**1. Урам тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләр һәм аларның астындагы мәйданчыкларны, бүленеш пунктларын һәм электр бәйләнешләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен багышланган башка җиһазларны ремонтлау:**

- урам яктырту челтәрләрен ремонтлау;
- урам яктырту челтәрләренә техник хезмәт күрсәтүгә килешү буенча хезмәтләр өчен түләү, светодиод лампалар сатып алу;

**2. Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:**

- Су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, аварияләрне бетерү;

**3. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:**

- гидрантлар сатып алу һәм урнаштыру;

**4. Торак пункт чикләрендә җирле мәгънәдә гомуми файдаланучы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту:**

- Түреш авылы эчендәге юлларны кышкы көне карап тору Урман урамы ;
- Түреш авылы эчендәге юлларны җәй көне карап тору Урман урамы;
- Юл буендагы үләннәрне чабу;

**5. Торак пункт территориясен төзекләндерү:**

- халыкның күпләп ял итү территорияләрендә үләннәрне чабу;

**6. Традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү:**

- Түреш авылы зиратының инвентарь йортын ремонтлау;
- Түреш авылы зиратыннан каты коммуналь калдыкларны туплау һәм ташу эшчәнлеген оештыру;
- Түреш авылы зиратлары территориясендә үләннәрне чабу;

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 22 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 15.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
Гражданнар җыенында катнашкан 15 кеше «РИЗА» позициясе өчен,
0 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:
1.Татарстан Республикасы Мөслим униципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегенең Түреш торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегенең Түреш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга 1500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларына, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар һәм локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 750 (җиде йөз илле) сум күләмендә үзара салым кертергә.
3. Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән һәм контракт төзегән гражданнарны, хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә.
4. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруга юнәлтү:

1. **Урам тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләр һәм**
**1. Урам тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләр һәм** **аларның астындагы мәйданчыкларны, бүленеш пунктларын һәм электр бәйләнешләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен багышланган башка җиһазларны ремонтлау:**

- урам яктырту челтәрләрен ремонтлау;
- урам яктырту челтәрләренә техник хезмәт күрсәтүгә килешү буенча хезмәтләр өчен түләү, светодиод лампалар сатып алу;

**2. Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:**

- Су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, аварияләрне бетерү;

**3. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:**

- гидрантлар сатып алу һәм урнаштыру;

**4. Торак пункт чикләрендә җирле мәгънәдә гомуми файдаланучы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту:**

- Түреш авылы эчендәге юлларны кышкы көне карап тору Урман урамы ;
- Түреш авылы эчендәге юлларны җәй көне карап тору Урман урамы;
- Юл буендагы үләннәрне чабу;

**5. Торак пункт территориясен төзекләндерү:**

- халыкның күпләп ял итү территорияләрендә үләннәрне чабу;

**6. Традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү:**

- Түреш авылы зиратының инвентарь йортын ремонтлау;
- Түреш авылы зиратыннан каты коммуналь калдыкларны туплау һәм ташу эшчәнлеген оештыру;
- Түреш авылы зиратлары территориясендә үләннәрне чабу;

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Карамалы авыл җирлеге башлыгы И.Н.Кәримов